РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШИКШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422053, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шикши, ул.Школьная, 4
тел. (84362) 46-1-35

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕКШЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422053, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шекше авылы., Мәктәп урамы, 4 йорт
тел. (84362) 46-1-35

e-mail: Shik.Sab@tatar.ru

16 январь 2019 ел №2

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 февралендәге 9 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алуы, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны тормышка ашырудан кергән акчаларны күчерү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2018 елның 30 октябрендәге 387-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының 15.019 № 02-08-07-17-19 протесты нигезендә Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советы карар итте:

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе турында” 2014 ел, 28 февраль, 9 нчы карары белән расланган нигезләмәгә, түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 2 абзацында «хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләрен "даими (штат) нигездә комиссиядә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shikshi бастырып чыгарырга.

Шекше авыл җирлеге башлыгы: Р. Р. Хайртдинов